КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 февраль г.Казань № 84

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 498 нче; 2016 ел, 8 май, 287 нче; 2016 ел, 18 июнь, 413 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 705 нче, 2019 ел, 08 февраль, 82 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

III бүлекнең 3.5 пунктындагы 3.5.5 пунктчаның беренче абзацында «авыл җирендә яшиләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин